**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 25 май | № 373

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары турында» 2014 ел, 22 август, 605 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары турында» 2014 ел, 22 август, 605 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган 2015 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ һәм перитонеаль диализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнарда:

1.1 һәм 1.2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «1.1. | Җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җәмгыяте үзәге, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академик Королев урамы, 4а йорты адресы буенча урнашкан | 1 процедурага 70,0 евро һәм 1 245 сумга эквивалент сумма |
| 1.2. | Җаваплылыгы чикләнгән «HD заманча медицина клиникасы» җәмгыяте үзәге, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 2 йорт, литер Ж адресы буенча урнашкан | 1 процедурага 70,0 евро һәм 1 245 сумга эквивалент сумма». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\373.doc